ОМСКИ ТАТАРЛАРЫ ГАЗЕТАСЫ

# ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

12 (101)
Декабрь 2013
Газета издается с декабря 2003 г.

# ТАТАРСКИЙ МИР

Просим бережно относиться к газете, в ней текст Священного Корана

# С ЮБИЛЕЕМ! ЮБИЛЕЙ БЕЛӘН!

***УВАЖАЕМЫЙ КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ И ЧИТАТЕЛИ ГАЗЕТЫ «ТАТАР ДӨНЬЯСЫ – ТАТАРСКИЙ МИР»!***



***Искренне поздравляю вас с 10-летием со дня выхода первого номера газеты «ТАТАР ДӨНЬЯСЫ – Татарский мир»!***

За эти годы «Татарский мир» завоевал репутацию востребованного издания. У газеты сложился свой круг постоянных читателей, сформировался интересный творческий коллектив редакции. Свежий номер «Татарского мира» с нетерпением ожидают не только горожане, но и жители самых отдаленных уголков нашей области.

Спустя десять лет можно с уверенностью сказать, что издание прошло испытание временем, заняло достойное место среди печатных средств массовой информации региона. Объективное и вдумчивое освещение социальных, экономических, исторических и культурных событий, национальный колорит в содержании материалов позволяют газете оставаться современной, актуальной и интересной. Большого уважения заслуживает предназначение издания «ТАТАР ДӨНЬЯСЫ – Татарский мир» – доносить до читателя вечные духовно-нравственные и культурные ценности, присущие татарскому народу, добрыми примерами согревать сердца людей. Материалы газеты служат развитию дружбы и взаимопонимания между представителями разных национальностей, проживающих на территории Омской области.

От всей души желаю коллективу редакции газеты «Татарский мир» новых успехов! Уверен, вы и впредь будете радовать своих читателей интересными и актуальными материалами.

Здоровья, благополучия, удачи во всех делах и начинаниях!

***Губернатор Омской области, Председатель Правительства Омской области В.И. Назаров***

***Хөрмәтле «Татар дөньясы» газетасы хезмәткәрләре!***



Себер җирендә, Омск каласында нәшер ителә торган "Татар дөньясы" газетасы дистә ел дәвамында милләттәшләребезне чын мәгънәсендә татар рухында тәрбияләп тора. Аның үзенә генә хас тоткан юлы, кыйбласы бар. Ул татар халкына хезмәт итә һәм башка милләтләр белән дуслык мөнәсәбәтләрен ныгытучы ролен дә үти.

Газета битләрендә урын алган төрле жанрдагы кызыклы язмалар тирән эчтәлеккә ия һәм мәгънәви яктан укучылар таләбенә җавап бирә. Мәкаләләре эчкерсез һәм объектив булуы белән аерылып тора. Газета сәхифәләрендә хезмәт кешеләре, аларның игелекле эшләре, уй-фикерләре тасфирлана.

Редакция коллективына һәм авторларга, аның төп иганәчесе Тамир Алимбаевка иҗади рух, бөтен кешелек өчен уртак кыйммәтләргә тугрылык һәм киләчәккә омтылыш хас. Халкыбызны ярату, эшкә чын күңелдән бирелгәнлек, энтузиазм һәм, иң мөһиме – хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгы, "Татар дөньясы"н файдалы һәм йогынтылы мәгълүмат үзәгенә әверелдерде. 10 ел эчендә күпләгән сынаулар үтелгән, тиешле тәҗрибә тупланган.

Хөрмәтле "Татар дөньясы" газетасы хезмәткәрләре! Сезнең барыгызга да сәламәтлек, бәхет, илһам, яңа кызыклы темалар һәм проектлар, укучыларның чиксез мәхәббәтен телим. Басмагыз киләчәктә дә тормышыгызга изгелек, оптимизм, матурлык өстәр, һәм ул һәрвакыттагыча заманабыз белән бергә атлап дип ышанып калам.

***Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов***



***Дорогие друзья!***

***Поздравляю коллектив редакции и читателей газеты «Татарский мир» со знаменательной датой – 10-летием со дня выхода первого номера издания.***

Все эти годы газета выполняет важнейшую миссию: способствует сохранению и развитию самобытной культуры, языка и традиций татарского народа, тем самым помогает поддержанию межнационального согласия на территории города Омска.

Вокруг издания объединились талантливые, увлеченные люди, пропагандирующие традиционные духовные ценности, вносящие значительный вклад в дружбу между разными этносами, живущими на нашей малой Родине.

Неудивительно, что газета «Татарский мир» пользуется заслуженным авторитетом среди членов Омской городской татарской национально-культурной автономии, а количество ее преданных читателей с каждым годом растет.

Пусть и впредь дружному коллективу издания и его читателям сопутствует успех во всех добрых начинаниях! Счастья и здоровья вам, вашим родным и близким.

***Мэр города Омска В.В. Двораковский***

***Кадерле дуслар, хөрмәтле милләттәшләр!***



Егерме беренче гасыр башында Омскида "Татар дөньясы" газетасы аваз салды. Заман белән бергә атлап барган газета бүген үзенең 10 еллыгын бәйрәм итә. Сезнең басманың кабатланмас үз язу рәвеше, үзенең эзлекле кыйбласы бар. Язмаларның төп геройлары – халкыбызның киләчәген тәрбияләүче һәм белем бирүче мөгаллимнәр, мәдәният хезмәткәрләре, тырыш халкыбыз. Сез аларның игелекле эшләрен, уй-фикерләрен укучыларга җиткереп әһәмиятле эш башкарасыз. Бүгенге көндә газетагыз Омски өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезне берләштерүче динамик үсештәге басма.

Барыгызны да «Татар дөньясы»ның юбилее белән ихлас күңелдән котлыйм, милләтебезнең киләчәген кайгыртып яшәвегезне телим. Сезгә иҗади уңышлар, ныклы сәламәтлек, гаилә бәхете юлдаш булсын. Татар халкының үткәнен, бүгенгесен, киләчәген дөрес яктыртучы басма булып калыгыз!

***Хөрмәт белән, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Р.З. Закиров***



РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
TATMEDIA
РЕСПУБЛИКАНСКОЕ АГЕНТСТВО ПО ПЕЧАТИ И МАССОВЫМ КОММУНИКАЦИЯМ

БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО

ОМСК ӨЛКӘСЕНДӘ БАСЫЛЫП ЧЫГУЧЫ
«Татар дөньясы» газетасы редакциясенә
милли матбугатыбызны саклап калу һәм үстерүгә зур өлеш кертүегез өчен

С уважением,
Руководитель И. МИННАХМЕТОВ

КАЗАНЬ 2013



***От имени централизованной религиозной организации «Духовное управление мусульман Сибири» и лично от себя выражаю самые теплые поздравления с вашим 10-летним юбилеем.***

Сегодня можно с уверенностью сказать, что газета «Татар дөньясы» прошла испытание временем, заняла свою нишу среди всех средств массовой информации, завоевала своего читателя. Вас отличает высочайшая степень достоверности, блестящий собственный стиль. Считается, что в юбилейные дни подводят итоги. Но это и прекрасное время для начала новых дел. Пусть все дни рождения вашего издания станут поводом не только для гордости за уже сделанное, но и стартом новых интересных проектов, и вам всегда будет светить путеводная звезда, которая поможет не сбиться с пути. Желаю всему коллективу газеты здоровья, неисчерпаемой энергии, творческих успехов и признания читателей!

***С добрыми молитвами и наилучшими пожеланиями, муфтий ЦРО ДУМ Сибири Зулькарнай Шакирзянович Шакирзянов***



***Дорогие друзья!***

***От всей души поздравляю вас с юбилеем!***

За 10 лет газета нашла своих читателей, стала популярной в городе и области и действительно любимой среди татарского населения. На страницах газеты читатели находят разнообразную информацию, но суть всех публикаций – призывы к любви, добру и созиданию, уважению национальных обычаев и традиций. А в многонациональном регионе это дорогого стоит!

И в том, что люди татарской национальности чувствуют себя в Омске членами одной семьи, большая заслуга и вашего издания.

Желаю коллективу редакции верных читателей, творческого долголетия и удачи!

***С уважением, Олег Смолин, первый заместитель председателя Комитета по образованию Государственной Думы***

# В ЭТОМ СМЫСЛ ЖИЗНИ

*Зульфия Ахмадеева*

***В течение 10 лет, с декабря 2003 года, издается «Татарский мир» – газета, которую с нетерпением ждут в каждом татарском доме нашей области, которую читает стар и млад. Газета, объединяющая татарский мир региона, освещающая богатую культуру, духовность, древнюю историю, оказывающая содействие этнокультурному развитию татар Омской области. Учредитель газеты – Тамир Алимбаевич Алимбаев. Издатель – Омская городская татарская национально-культурная автономия, председателем совета которой является Тамир Алимбаевич.***

В преддверии юбилея мне захотелось пообщаться с тем человеком, кто вот уже целое десятилетие удивляет своей бескорыстностью многих, задать ему несколько вопросов. Но, так как он постоянно в разъездах (вот и на этот раз уехал в Казань на итоговое заседание исполкома Всемирного конгресса татар, членом которого является), мне пришлось до назначенной встречи познакомиться с ним заочно по многочисленным публикациям о нем в различных изданиях, по его монографии «Материально-техническое обеспечение регионального АКП».

Тамир Алимбаевич – человек, известный в бизнесе не только в нашем регионе, но и в других регионах нашей страны, в европейских странах, создавший в Сибири крупную многопрофильную структуру по материально-техническому обеспечению в сфере агропромышленного комплекса – ООО «Корпорация «Енисей». Возглавляемая им компания занимается продажей сельскохозяйственной техники, запчастей к ней, предпродажным и гарантийным обслуживанием техники. Компания является дилером российских заводов, а также предприятий Украины, Белоруссии. Динамично развивается, открывает свои филиалы и торговые представительства в Омской, Новосибирской,



Тюменской, Курганской, Челябинской, Кемеровской областях, Алтайском крае, Республике Казахстан – более 140 филиалов.

Имея много филиалов, расположенных на большом географическом пространстве, Тамир Алимбаевич организовал транспортно-логистический центр по завозу, переработке (сортировке) и вывозу большого количества товара. И всё это посредством своего транспорта.

Тамир Алимбаевич окончил факультет механизации Омского сельскохозяйственного института и Институт бизнеса и делового администрирования Академии народного хозяйства при Правительстве РФ. Кандидат экономических наук. Занимается научно-исследовательской деятельностью, разработчик научных тем и автор публикаций по проблемам производственно-технического обеспечения АПК. Находясь в экономически развитых странах, таких как: Соединенные Штаты Америки, Германия, Франция, Италия, Великобритания, он непосредственно на местах изучал систему материально-технического обеспечения агропромышленного комплекса.

Президент ООО «Корпорация «Енисей» входит в первую десятку наиболее успешных бизнесменов-руководителей. Он победитель конкурса «Управленец года-2005» в номинации «Магистр управления в сфере бизнеса», фамилия Т.А. Алимбаева включена в бизнес-рейтинг «Ассоциация менеджеров – 1000 самых профессиональных менеджеров России». Информация о Тамире Алимбаевиче внесена в энциклопедию «Лучшие люди России». Он член Омского областного Союза предпринимателей (1 гильдия), член правления Торгово-промышленной палаты Российской Федерации.

Безупречный многолетний труд, профессионализм, активная жизненная позиция увенчаны общественными и ведомственными медалями и орденами: за профессионализм – медали «За безупречную службу в органах МВД» (г. Москва), «200 лет МВД России»; за стратегический менеджмент – «Золотая медаль Французской Ассоциации содействия промышленности» (Париж); за благотворительную деятельность – орден «Меценат» (г. Москва); за созидательный труд во славу Отечества – орден «Звезда Созидания» (г. Санкт-Петербург); премия им. Минина и Пожарского «Достойному гражданину – благодарная Россия» (г. Москва); медаль «В память 1000-летия Казани» (г. Казань); медаль «За большие заслуги перед татарским народом» (г. Казань), благодарственное письмо Президента Татарстана М.Ш. Шаймиева.

После ознакомления с его монографией, публикациями о нем я задала единственный вопрос:

**– Тамир Алимбаевич, все эти награды – наглядное подтверждение Вашей жизненной позиции. Самым важным в Вашем вкладе в развитие языка, культуры и традиций татарского народа являются: издание и бесплатное распространение 2500 экземпляров газеты «Татарский мир», руководство Омской городской национально-культурной автономией и ее материальное обеспечение, многолетняя поддержка татарско-башкирского ансамбля «Умырзая», материальная помощь детским домам, садикам, школам и всем тем, кто нуждается в Вашей помощи. Вы никогда не отказываете, никому не говорите «нет». Как Вам это удается? Почему Вы это делаете?**

– Почему финансирую «Татарский мир», ансамбль «Умырзая», помогаю социальной сфере? Ну не потому, что мне деньги девать некуда. Не всё меряется деньгами. Есть понимание добра, справедливости, ценностей и, в общем, смысла ЖИЗНИ.

## Фидакарь хезмәттә – милләт сагында

*Хәлил Садыйков*

***Тамир Алимбай улы Алимбаев – Себер татарлары арасында иң күренекле шәхесләрдән санала. Тормыш юлы һәм хезмәте татар яшьләре өчен бик күркәм үрнәк булып тора. Аның табигате, Ходай биргән сыйфатлары - күпкырлы талант, әдәплелек, үтә инсафлылык, тирә-як мохиткә зарар, көндәшләренә (конкурент, дип аңлагыз) авырлык китермичә киеренке ситуацияләрдән чыга белү һәм башкалар.***

Ул бай белемен үзе җитәкләгән «Енисей» ширкәте эшчәнлегендә куллана белә һәм даими рәвештә яңадан-яңа уңышларга ирешә. Тамир Алимбай улы – юмарт меценат. Татар ренессансына (яңарышына) ышаныч һәм дәреслек белән хезмәт итә торган зур шәхес. Авыл, районнардагы Сабан туе кебек зур күләмле чараларның чыгымнарын да үз өстенә ала торган эшмәкәр. Өлкәдә эшләүче мәчетләрнең шактые аның ярдәмендә төзелде. 2003 елның декабрь аеннан бирле «Татар дөньясы» дип исемләнгән тулы төсле, зур күләмле газетаны (999 данә) финанслый һәм тулысынча укучыларга бушлай тарата да. 2011 елдан башлап газета 2500 тираж-лы булып нәшер ителә.

Омски татарлары газетасы хәзер өлкәдә генә түгел, Мәскәү, Казан, Чиләбе, Уфа, Курган, Төмән, Тубыл, Новосибирски, Томски, Барнаул һәм башка шәһәрләргә дә төрле юллар белән җиткерелә. Газетада Омски өлкәсе татарларының тормышы, барлык яңалыклары тасвирлана, башка төбәкләрдә һәм шулай ук Татарстанда яшәүче милләттәшләребез тормышы да читтә калмый. «Татар дөньясы» укучыларның яратып укый торган мәгълүмат чыганагына әверелде.

2013 елның декабрендә «Татар дөньясы» газетасына 10 яшь тула. Газетаны яратып укучылар Тамир Алимбай улына ныклы сәламәтлек, «Енисей» ширкәтенә зур уңышлар, ә газетага татар телен үстерүгә һәм саклауга кагылышлы проблемаларны күбрәк чагылдыруын теләп калалар.

# Тынгы белмәс җаннар

*Фагыйлә Чумарова*

***Омски өлкәсендә татарлар өчен бүгенге көндә бердәнбер мәгълүмат чарасы булган «Татар дөньясы» газетасының нәшер ителә башлавына декабрь аенда 10 ел тула. Шул дәвердә «Татар дөньясы»-ның редколлегиясе төрле үзгәрешләр кичерде. Әлбәттә, һәр кеше үз эзен калдырды кебек. Шулай да, бүгенге көнгәчә газетабызга тугрылыклы булып калучылар юк түгел, һәм аларсыз газетаны күзаллау мөмкин дә түгел кебек. Кемнәр соң алар?***



Иң беренчеләрдән булып Сания апа Анненкова турында язасым килә. Сания апа яше буенча да, беренче көннәрдән үк газетада язмаларын бастырып торучы буларак та хөрмәткә лаек кеше. Аның язмаларының геройлары – мәшһүр татар халкының күренекле шәхесләре. Сания апа алар турында илһамланып, аларны яратып күзаллый белә, шулай ук укучыларга бик үтемле итеп җиткерә. Аның шундый осталыгына, эшчәнлегенә сокланмый калып булмый соң!

Тормышның тоткасы – тынгы белмәс җаннардан торадыр. Нәкъ менә шундый кешеләр тормышта нинди дә үзгәрешләр, ачышлар барлыкка китерә, могҗизалар тудыра. Сания Сабир кызы Мирхалеева менә шундыйларның берсе инде! Безнең Омски шәһәрендә татар җәмәгатьчелеге эшләрен алып баручы, аларны тормышка ашыру өчен күп көч куйган кешеләрнең берсе ул.

Белгәнебезчә, Омски шәһәренең җирле телевидениесендә берничә ел татарлар турында эчтәлекле тапшыру алып баручы да, соңрак, 10 елга якын, «Иртеш» Өлкә дәүләт телерадио ширкәтендә Сайганова Розалия ханым белән «Сәлам» тапшыруын алып баручы да, ә бүгенге көндә бөтендөнья «Азатлык» радиосына хәбәрләр биреп торучы да – Сания апа! Энергиясе ташып торган акыллы, белемле Сания апа һәрвакыт ярдәмгә килергә тора, вакытында киңәшләрен бирә; кешеләр белән бик тиз уртак тел таба һәм һәр кешегә олы шәхес итеп карый белә. Сания апа белән сөгатьләр буе әңгәмә корып, сөйләшеп утырсаң да, бер дә ялыктырмый – ул кызыклы әңгәмәдәш. Чын журналист дәрәҗәсенә күтәрелгән шәхес ул!

Әгәр синең фикердәшләрең, башкарган эшләреңдә булышчың булмаса – күп эш майтара алмыйсың. Тормыш агымы Сания апаны шушы эшләренең башында ук теләктәше, фикердәш дусты Розалия апа белән очраштырган. Розалия Мәгариф кызы Сайганова Сания апа белән бергәттән «татар эшенә» җигелеп, бүгенгә хәтле аңа тугрылыклы булып кала алды. Ә инде соңгы елларда шәһәр милли-мәдәни автономиясе каршында башкарылып килгән барлык эшләрне үз җилкәсенә алды, дип әйтсәк тә ялгыш булмас. Кешелеклелеге ягын күзаллаганда – Розалия ханымның сабырлыгына, һәркемнең күңел кылларын җилкендерерлек иплелегенә сокланмый булмады соң!

Газетабыз редколлегиясендә ялгыш килеп кергән бер кеше дә юктыр. Татарның язмышына, татар теленә битараф кала алмаган кешеләр эшли монда. Нурия апа Кучукова да менә шундыйларның берсе, ул да, шулай ук, татар эшендә һәрвакыт алдынгылардан булып саналды. Нурия апа озак еллар татар телен укытты – берничә ел Омскиның 105, 57 нче гомуми белем бирү мәктәпләрендә факультатив дәресләр алып барды, аннан соң шәһәребезнең милли-мәдәни автономиясе каршында эшләүче «Өмет» үрнәк студиясенә йөрүче балаларга татар телен өйрәтте. Газета чыгаруда да аның өлеше зур – татар телендә язылган мәкаләләрне тикшерүче-корректор да – Нурия апа.

Редакция коллективы турында сөйли башлагач, берникадәр үзем турында да язып, хисләремне белдереп үтмәсәм, дөрес булмас кебек... Мин шундый олы шәхесләр арасында булуыма чиксез шатмын! Газета редколлегиясенә керермен диган уй - хыялымда да булмады! Шулай да, сирәк кенә булса да, кечкенә генә мәкаләләр язгалый идем. Редакторыбыз Гөлсинә ханым мине газетага чакыргач, башларым күккә тигәндәй булды! Кайсын гына алсам да, бу зур тәҗрибәле, үз эшләренең остасы булган хөрмәтле ханымнардан үрнәк алып, һаман алардан өйрәнеп эшләргә тырышам.

Ә инде газетабызның нинди булуы мөхәррирдән, аның акыл байлыгыннан, сәяси сизгерлегеннән, хәлне алдан күрә, сиземли белүеннән, кешеләр белән уртак тел таба алуыннан тора. Газетабызның мөхәррире Гөлсинә ханым Ахмерова нәкъ менә шул сыйфатларга ия. Аның җитәкчелегендә коллектив эшкә сәләтле, бербөтен булып, яхшы газета чыгара алу дәрәҗәсенә ирешә.

Газетада эчтәлек кенә түгел, тышкы як та бик мөһим. Ун ел дәвамында диярлек газетабызның бизәлеше «Енисей» корпорациясенең реклама бүлеге башлыгы Наталья Баканова тарафыннан тәэмин ителеп торды. Соңгы елда, декрет ялга киткәнче, «Татар дөньясы»ның бизәлешен Диләрә Ахтичанова башкарды. Яшь кенә булуына карамастан, сокланырлык итеп эшли белә ул!

Газетабызда эшләүчеләрнең барысын да 10 еллык юбилей белән тәбрикләп, озын-озак еллар нәшер ителүен телисе генә кала!

# БЕЗ - БЕРГӘ!

*Гөлсинә Ахмерова*

***5 декабрь көнне «Татмедиа» агентлыгына Россия төбәкләрендә: Башкортостанда, Удмуртиядә, Чувашстанда, Ульяновскида, Самарада, Екатеринбургта, Төмәндә, Омскида һ.б. чыгучы татар газеталарының җитәкчеләре еллык киңәшмәгә җыелды. Мондый семинар-киңәшмә инде өченче ел рәттән Татарстан хөкүмәтенең «Татмедиа» агентлыгы тарафыннан оештырылган «Атна вакыйгалары» кушымтасы нәшер ителә башлаганнан үткәрелеп килә.***

Киңәшмәдә шулай ук Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Ирек Миннәхмәтов,«Татмедиа» ААҖнең генераль директоры Фәрит Шаһиәхмәтов, аның киңәшчесе Ислам Әхмәтҗанов, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Татарстан халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов, «Шәһри Казан» газетасы, «Атна вакыйгалары» кушымтасы мөхәррире Мансур Мортазин катнашты.

Киңәшмәне Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Ирек Миннәхмәтов ачып җибәрде. «Татар кушымтасына ихтыяҗ барын беләбез, «Атна вакыйгалары» була торып, ник аена бер мәртәбә генә чыга дигән борчуларыгыз да безгә килеп ирешә. Әмма ләкин әлегә финанс мәсьәләсе шактый авыр. Яхшысына өметләник, ләкин булганына канәгатьләник, булганының кадерен белик. Тиражларыбызны арттырыйк. Халкыбыз яратып укый торган газета әзерлик. Хәзер инде «Атна вакыйгалары»ның электрон версиясе дә эшли башлады. Бу эш республика Президенты кушуы буенча башкарылды», - диде ул һәм киңәшмә делегатларына уңышлар теләде.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров үзенең чыгышында: «Газета уку – халкыбызның гомер-гомергә яраткан шөгыле. Төбәкләрдә нәшер ителүче милли басмалар милләтне саклап калучы бер чара. Омскилыларның «Татар дөньясы» газетасы - милләткә хезмәт итә торган газета», - дип ассызыклап үтте.

«Шәһри Казан» һәм «Атна вакыйгалары» газеталары баш мөхәррире Мансур Мортазин: «Татарстан Республикасының кушымтаны нәшер итүе татарларны берләштерүдә иң көчле проектларның берсе булды, - диде. - Проект эшли, халык кабул итте. Менә инде исеменең җисеменә туры килмәвен күздә тотып, озак киңәшләшүләрдән соң, кушымтаның исемен үзгәртә алдык. Яңа елдан ул «Без - бергә» дигән исем астында дөнья күрәчәк».

Семинар-киңәшмәдән соң «Татмедиа» җитәкчелеге юбилярларны тәбрикләде. 10 еллыгы уңаеннан котлауларны «Татар дөньясы» газетасы да кабул итте.





## Казан

***Хөрмәтле Омски татарлары!***

«Татар дөньясы» газетасының чыга башлавына 10 ел тулу уңаеннан тәбрикләүләремне кабул итегез. «Татар дөньясы» - зәвыклы, бай эчтәлекле һәм төсле матур газета. Милләттәшләребез өчен бер генә татарча матбугат та чыкмаган буш урында сезнең шушы газетаны чыгару эшенә алынуыгыз үзенә күрә зур бер батырлык. Себер якларында яшәүче халкыбызның милләтен, телен, динен саклап калуда тырышлыгыгыз өчен рәхмәт сезгә. «Татар дөньясы»н гамәлгә куючы Тамир Алимбай улы Алимбаевка да чиксез рәхмәтлебез. Әгәр Тамир әфәнде кебек милли җанлы эшмәкәрләребез күбрәк булса, татар халкының киләчәге дә өметле.

Газетагыз матур эчтәлекле, халык өчен файдалы булсын, укучыларыгыз да артсын. Татар газетасын нәшер итү эшенә алынганыгыз өчен Ходай сезгә бер дә искә алмаган, көтмәгән җирдән ярдәм бирсен.

«Шәһри Казан» һәм «Без – бергә» газеталары редакциясе дә бу теләкләргә бик теләп кушыла. «Татар дөньясы»на «Без – бергә» һәм «Шәһри Казан» газеталары белән гел бергә булырга язсын.



***Хөрмәт белән, «Шәһри Казан» һәм «Без – бергә» газеталары баш мөхәррире Мансур Мортазин***

## Төмән

***Хөрмәтле «Татар дөньясы» газетасы коллективы!***

Сезне 10 ел буе төбәгегез татарларының теле, мәдәнияте, тарихын үстерүдә армый-талмый эшләвегез, халкыбызның туган телдә укуга сусавын басуыгыз, яңадан-яңа иҗат әһелләре тудыруга чиксез өлеш кертүегез белән котлыйбыз. «Татар дөньясы» ул – күңел азыгы, фикер сафлыгы, акыл агышы, тормыш барышы. Ул шулай ук – иман, саф күңел, сәламәт тормыш, киңәшләр, дөрес көнкүреш тә әле. Аның файдалы сыйфатларын санап бетерерлек түгел. «Татар дөньясы» көч бирә, хәл кертә, тормышыбызны яктыртып, баетып тора. Газета халыкны тугры караш-



ка, төпле акылга ия булырга һәм хезмәт сөяргә чакыра. Юбилеегыз белән котлап, себерчә нык сәламәтлек, иҗат уңышлары, тугры дус, фикердәшләр телибез. Газетагызны һәр өйдә түземсезлек белән көтеп алсыннар. Һәрвакыт үткен телле, кайнар йөрәкле милләт сакчысы булыгыз!

***Төмән өлкәсенең «Яңарыш» газетасы редакциясе коллективы исеменнән баш мөхәррир Алсу Сәгыйтова, «Әдәби Төмән» иҗат берләшмәсе әгъзалары***

## Удмуртия



***Хөрмәтле каләмдәшләребез һәм «Татар дөньясы» газетасын укучылар»!***

10 ел элек Омскида газета чыга башлау – милли уяну үсүне, сәяси өлгергәнлеккә омтылуны аңлатучы зур тарихи вакыйга. Ул бәгырьләрдән саркып чыккан җан сүзенә, ана телендә аралашуга сусаган омскилылар өчен көтеп алынган зур бүләк булу белән берррәттән, күңелләрдәге милли гамьне кабат кузгатып җибәргән. Сезнең басманың кабатланмас язу рәвеше, үз позициясе бар. Язмаларның төп геройлары – хезмәт кешеләре, аларның игелекле эшләре, уй-фикерләре. Бу изге эшне башлап җибәрүче һәм дистә ел дәвамында үзенең шәхси акчасы хисабына алып баручы Тамир Алимбаевның һәм газетаның баш редакторы Гөлсинә ханымның фидакарь хезмәте аеруча мактауга һәм хөрмәткә лаек. Чын күңелдән үз эшләренә бирелгән бу мөхтәрәм милләттәшләребезгә, авторларга иҗади рух, гомумкешелек кыйммәтләренә тугрылык һәм киләчәккә омтылыш хас. Алар бүгенге көндә татарлар күпләп яшәүче төбәкләргә үрнәк булырдай әйтеп бетергесез мөһим эш башкаралар. Халкыбызны ярату, эшкә чын күңелдән бирелгәнлек, һөнәри осталык газетаның сыйфатында да чагыла. Газетаның тугрылыклы укучылары арасында «Яңарыш» газетасы редакциясендә күп еллар эшләп киткән, бүгенге көндә Большеречьедә яшәүче Роза ханым Хәйруллинаның булуы элемтә җепләребезне тагын да ныгыта. Сезне газетаның юбилее һәм якынлашып килүче Яңа ел бәйрәме белән чын күңелдән тәбриклибез. Барыгызга да сәламәтлек, бәхет, илһам, яңа кызыклы темалар һәм проектлар, укучыларның чиксез мәхәббәтен телибез. Киләчәктә дә укучылар күңеленә изгелек, түземлелек, рухи кыйммәтләр орлыкларын чәчүне дәвам итүгезне телибез.

***Удмуртиядә нәшер ителүче «Яңарыш» газетасы редакциясе баш мөхәррире Рәмзия Габбасова***

## Башкортостан



***Хөрмәтле хезмәттәшләребезне, Омски татарларының «Татар дөньясы» гәзите редакциясен һәм укучыларын матур юбилейләры уңаеннан кайнар котлыйбыз!***

Безне дустыбыз «Атна вакыйгалары» гәзите таныштырды. Һәркайсыбыз бер үк максатка хезмәт итәбез: дөнья буйлап сибелгән милләттәшләребезне берләштерәбез. Татар теле, сүзе – безнең иң зур байлыгыбыз. Берсеннән-берсе кызыклы һәм фәһемле язмаларыбыз ак кәгазьгә төшеп, күз нурларыбыз, күңел җылысы белән укучыларга юллана. «Диләфрүз» гәзите Сезгә сеңел генә, аңа нибары өч яшь. Ул Русиянең төрле төбәкләрендә яшәүче хатын-кызлар өчен татар телендә нәшер ителә. Шулай ук Омски якларында да укучыларыбыз бар, ә безне иң күп яздырып алучылар Тевриз районында. Аларга кайнар сәламнәребезне юллыйбыз.

Омски татарлары газетасы – «Татар дөньясы» - милләтпәрвәр җанлы кешеләрнең фидакарь хезмәт нәтиҗәсе. Ихлас соклану һәм горурлык белән дистә еллык тарихы булган тәҗрибәле басмагызга иҗади уңышлар, заман таләпләреннән калышмыйча, зур юллар үтүегезне телибез. Бергә-бергә иҗат дөньясында кайнап, матур җимешләребез белән укучыларны шатландырып торыйк!

***Иң изге теләкләр белән «Диләфрүз» редакциясе хезмәткәрләре***

## Самара

***Омски татарларының «Татар дөньясы» газетасына – 10 яшь!***

***Хөрмәтле Тамир Алимбаевич, Гөлсинә ханым!***

Сезне һәм «Татар дөньясы» газетасының укучыларын 10 еллык юбилеегыз белән чын күңелебездән котлыйбыз.

Сезнең басмагызны кулыбызга алгач, аның уңышларын күреп куанабыз, сокланабыз. Татар җанлы эшкуарларыбызның берсе - Тамир Алимбай улы Алимбаевның юмартлыгына ис китәрлек. Ун ел дәвамында шушындый яхшы сыйфат һәм зәвык белән, затлы кәгазьдә, күп төсләрдә эшләнгән басманы хәләл шәхси акчасына туган халкына бушлай җиткереп торучы шәхес белән горурланмыйча мөмкин түгел.

«Татар дөньясы» газетасының төрле бәйгеләрдә, конкурсларда катнашып, призлы урыннар алуы да күп нәрсә турында сөйли түгелме?! Киләчәктә дә «Татар дөньясы» яшәр,



милләтебезне үзенең матур язмалары белән гел куандырып торыр дип ышанабыз.

Анда күбрәк татарча язмалар урын алсын, газетаны өйләренә яздырып алучылар саны артсын иде.

Сезнең барыгызга да исәнлек-саулык, күңел тынычлыгы, гаилә бәхете, иҗади уңышлар телибез. 10 яшьлек юбилеегыз котлы булсын!

***Олуг хөрмәт белән, 24 ел дәвамында укучыларын куандырып торучы, 3500 данә белән нәшер ителүче Самара өлкәсе татарларының «Бердәмлек» газетасы хезмәткәрләре исеменнән аның баш мөхәррире – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Самара өлкәсе губернаторының «Во благо земли Самарской» Мактау билгесе иясе Рәфгать Әһлиуллин. Декабрь 2013 ел***

*Сания Искандеровна Анненкова*

# ТАТАРЫ В СРЕДНЕЙ АЗИИ

***Как известно, наши татары, не потеряв себя, успешно прошли свой особый, сложный путь развития.***

***Они вправе гордиться собственной историей и тем, что сумели сберечь в своем сердце религию добра и мира Ислам, родной язык и самобытную культуру.***

***Об этих татарах, волей судеб оказавшихся на земле Средней Азии с изначальным названием Туркестан, хотелось бы мне немного поговорить с вами, уважаемые читатели.***

Исторически так сложилось, что местом компактного проживания татар были районы Поволжья, Урала и Сибири.

В X–XIV веках прародина татар – Волжская Булгария имела торговые и дипломатические отношения со странами Средней Азии, которые укрепились в период Казанского ханства в XV–XVI веках. Но после завоевания в 1552 году царем Иваном Грозным Казанского ханства, чтобы избежать насильственного крещения, многие татары вынуждены были бежать в разные края, в том числе и в Туркестан.

Местное население относилось к татарам с симпатией, как к единоверцам.

В 1885 году с окончательным завершением присоединения Средней Азии к России при царствовании императора Александра III особенно усилился приток татарского населения в Среднюю Азию.

Правительство России старалось наладить регулярные торговые отношения со Средней Азией с выгодным использованием татарских купцов. Татарское купечество с многочисленным окружением вселялось в окрестности города Ташкента, основывая большую татарскую общину.

В 1920–1930-е годы – в период раскулачивания, коллективизации и голода в России – происходил массовый приток татар в Узбекистан.

Дальнейший приток татар пришелся на годы Великой Отечественной войны.

В 1966 году, после землетрясения в городе Ташкенте, прошло еще одно переселение в Узбекистан – как татар, так и людей других национальностей – по призыву восстановления Ташкента, разрушенного ужасным землетрясением, которого боятся по сей день.

**На 1 апреля 2013 года, по данным статистики**, численность населения Узбекистана составила около 31 миллиона человек. Из них почти половина проживает в сельской местности.

Около полумиллиона татар живут в Узбекистане, из них в городе Ташкенте – около 280 тысяч человек.

Рождаемость превышает смертность в три с лишним раза!

Из 100% зарегистрированных браков распадается лишь 1%.

Численность людей, состоящих на учете как ищущие работу, на 1 апреля 2013 года составляла 10 тысяч человек.

Число прибывших в Узбекистан – 42 тысячи человек, а выбывших – 47 тысяч человек.



У монумента эмиру Тимуру (Тамерлану)

В реализации большинства инвестиций участие принимает Исламский банк развития.

С 1 мая 2013 года введен закон о принудительном лечении больных заразной формой туберкулеза в течение шести месяцев, вплоть до излечения в условиях госпитализации.

Согласно прописке лицам без гражданства разрешается постоянное проживание в Узбекистане, за исключением города Ташкента.

**Национально-культурные центры**

28 декабря 1989 года в Ташкенте был учрежден Устав Татаро-башкирского центра. А в 1993 году данный Устав был перерегистрирован под названием «Татарский общественно-культурный просветительский центр» (ТОКПЦ).

Также функционирует Республиканский интернациональный культурный центр – с объединением культурных центров всех национальностей, проживающих в Узбекистане.

В 90-е годы XX века были созданы татарские национальные культурные центры во многих городах Узбекистана: Бухаре, Самарканде, Фергане, Навои и др.

**Татарский общественно-культурный просветительский центр (ТОКПЦ) города Ташкента**

Деятельность центра:

1) Литературно-историческая деятельность (литературно-творческие вечера, концерты, выставки).

2) Изучение родного языка.

3) Теле-, радиопередачи (ведущая программ на татарском и башкирском языках – заслуженный работник культуры Республики Татарстан Райхан Манняпова).

4) Культурно-массовая работа среди молодежи. Руководитель – Нариман Каримов.

5) Культурно-массовая работа среди детей (обучение детей национальным танцам, песням, обычаям татар).

6) Благотворительная деятельность (посещение одиноких пожилых людей, детских учреждений, встречи с участниками Великой Отечественной войны и т. п.).

7) Женсовет (председатель – Наиля Терязова).

В концертных программах принимают участие фольклорные ансамбли города Ташкента. 50 лет служит народу ансамбль «Яшьлек», 25 лет – «Дуслык», 10 лет – «Булгар». Популярны татаро-башкирские фольклорные ансамбли «Шатлык», «Якташ», «Урал» и самодеятельные коллективы.

Возглавляет Татарский общественно-культурный просветительский центр заслуженный работник народного образования Узбекистана, профессор и проректор института физкультуры, мастер спорта Ришат Хисматулович Набиуллин.

Ни одна из знаменательных дат не проходит без внимания татарского центра.

Были проведены творческие вечера с концертами, посвященными 105-летнему юбилею со дня рождения выдающейся татарской актрисы, певицы, композитора Сары Садыковой; выставки картин известных художников Узбекистана, Татарстана; по телевидению знакомили население со Всемирным конгрессом татар (г. Казань). Прошли вечера, посвященные Дню Татарстана в Узбекистане с участием артистов из Татарстана.

Постоянно проводятся конкурсы молодых исполнителей с целью выявления лучших исполнителей татарских народных песен, танцев, а также произведений современных татарских композиторов.



Активисты Татарского общественного культурно-просветительского центра Ташкента

**5 мая 2013 года** на сцене Республиканского интернационального культурного центра г. Ташкента состоялся музыкально-поэтический вечер, посвященный памяти великих сынов татарского народа: поэта, Героя Советского Союза, отдавшего жизнь за Родину, Мусы Джалиля и писателя-публициста, драматурга, критика и политического деятеля Гаяза Исхаки. С докладами на татарском языке о жизни и творчестве этих героев выступили ученые-историки. В первой части вечера звучали стихи Мусы Джалиля из «Моабитской тетради» на татарском языке, а также песни на слова из незабываемых творений поэта.

Во второй части вечера прозвучали отдельные выдержки из известных произведений Гаяза Исхаки в музыкальном оформлении ансамбля «Булгары». С глубоким вниманием слушали присутствующие выступление землячки Гаяза Исхаки, гостьи из города Астрахани, руководителя объединения астраханских татар Наили Потеевой. Она является горячим последователем дела Гаяза Исхаки, вкладывает в развитие татарского языка и культуры большое усилие.

Прекрасный вечер завершился исполнением татарских и башкирских современных и народных песен, оставив в памяти людей неизгладимые впечатления.

**Сабантуй в Ташкенте собрал около 40 тысяч человек.**

9 июня 2013 года в центральном парке культуры и отдыха имени Бобура города Ташкента прошел татаро-башкирский национальный праздник Сабантуй с зажигательными танцами, душевными песнями, презентацией национальной кухни, спортивными состязаниями и народными играми.

Татары и башкиры Узбекистана отмечают праздник Сабантуй с начала 60-х годов. На праздник плуга съехались тысячи людей со всего Узбекистана, независимо от национальности и вероисповедания. Жителей и гостей столицы на открытии праздника тепло приветствовали Чрезвычайный и Полномочный Посол Российской Федерации в Узбекистане Владимир Тюрденев, председатель Комитета ветеранов войны Татарстана генерал-майор Ахат Юлашев, представитель Татарстана в Узбекистане Рамиль Шакиров, председатели Татарского общественного культурно-просветительского и Башкирского культурного центров Ришат Набиуллин и Ильшат Хасанов и многие другие ответственные работники Узбекистана.

Было зачитано приветственное послание Президента Татарстана Рустама Минниханова.

Программа мероприятий Сабантуя включала большой праздничный концерт с участием мастеров искусств Татарстана, Башкортостана, Узбекистана, творческого коллектива «Казан егетләре», ансамблей «Яшьлек», «Дуслык», «Булгар», а также самодеятельных коллективов. В их исполнении прозвучали классические и современные татарские, башкирские, русские и узбекские песни.

По всему парку культуры в течение дня проводились традиционные для Сабантуя конкурсы и состязания: перетягивание каната, бой мешками на бревне, бег с ведрами воды, лазание на столб за петухом, бег в мешках, бег с ложкой и яйцом, традиционный курэш, разбивание с завязанными глазами горшков и т. д.

Сабантуй в Ташкенте собрал около 40 тысяч человек. Празднование продолжалось до позднего вечера. По мнению гостей праздника, Сабантуй в Узбекистане давно превратился в интернациональное празднество, где с удовольствием гуляют и веселятся представители всех народностей, населяющих многонациональный Узбекистан. Сабантуй отметили и в Бухаре, Навои, Фергане, Самарканде, Зарафшане и других городах.

**В заключение этой статьи** хотелось бы поделиться с вами, дорогие читатели, мыслями о том, что, находясь в Ташкенте, невозможно не обратить внимания на памятник, высящийся на огромном пространстве центральной площади Ташкента, посвященный создателю Среднеазиатского государства (эмирата) Тимуру (Тамерлану) – 1336–1405 гг. – полководцу, с 1370 года – эмиру (главе) эмирата в Средней Азии.

На постаменте величественного монумента золотыми буквами **высечена надпись: «Сила – в справедливости»** на узбекском, русском, английском, арабском языках.

Разгромив Золотую Орду, на базе Чагатайского улуса, отделившегося из состава Золотой Орды, Тимур создал Среднеазиатское государство со столицей в Самарканде. Совершал походы в Иран, Закавказье, Индию, Малую Азию и другие страны.

В 1370–1507 годы Среднеазиатским государством правила основанная Тимуром династия Тимуридов. Наиболее известным из них был Бобур (1483–1530 гг.). Он в 1526 году основал в Индии династию Великих Моголов. В Узбекистане было отмечено 500-летие со дня рождения Бобура. Его именем назван центральный парк культуры и отдыха Ташкента, где проводится праздник Сабантуй, а также улица, на которой расположены татарские центры.

По всему следует, что в Узбекистане знают и помнят древнюю историю создания своего государства, воздавая почести лидерам.

Отрадно, что не позабыт в Узбекистане и наш выдающийся татарский поэт Габдулла Тукай. Имя его носит одна из центральных улиц столицы – Ташкента.

Мира и успехов в укреплении дружественных отношений между государствами Узбекистан и Россия!



Здание Ассамблеи государств в Ташкенте – в нем решаются задачи развития сотрудничества между странами – участницами Ассамблеи

# Милләт тормышының елъязмачысы...



***Омски өлкәсендә яшәүче хөрмәтле милләттәшләрем! Төмән җиреннән кайнар сәлам сезгә, кадерле дусларым: Розалия Сайганова, Сания Мирхалиева, Гөлсинә Ахмерова, Тамир Алимбаев һәм газиз милләтебезгә хезмәт итүче дусишләрем, танышбелешләрем!***

Сезнең барыгызны да туган ягыгызда мәгърифәт нурларын балкытучы «Татар дөньясы» гәзитегезнең 10 еллыгы белән ихлас күңелемнән котлыйм, бу нурлы басманың чиксез озын гомерле булуын, аны күз нурлары яктылыгында җан җылылары белән әзерләп дөньяга чыгаручыларга рәхмәтле укучыларының күбрәк булуын, шушы игелекле хезмәттә яңадан-яңа иҗади табышлар өстәлеп торуын телим.

Кызганыч ки, кулыма сирәк кенә килеп керә Омскиның «Татар дөньясы», миңа аны баш мөхәррире Гөлсинә ханым, актив хәбәрчеләре, редколлегия әгъзалары Сания һәм Розалия ханымнар Казанда, Төмәндә очрашулар вакытында бүләк итсәләр генә. Шул берәмләп кенә укылган саннарыннан да гәзитнең никадәр бай эчтәлекле, тирән мәгънәле булуы, югары профессиональ дәрәҗәдә эшләнелүе күренеп тора. Омск төбәге татарларының тормышы-көнкүреше, дини хисләре уянып иманга кайтулары, мәктәпләренең, туган телнең хәле, тарихы, мәдәни үсеше, үткән һәм бүгенге сагышлары, якты өметләре ачык чагыла бу гәзиттә. Омск татарлары милли үсешенең киң татар дөньясы, мәркәзебез Казан белән аерылгысыз тыгыз бәйләнешен күрсәтеп, милләтебезнең бербөтенлеген саклауга үзеннән саллы өлеш кертә гәзитегез. Аның тулы төсле булып затлы кәгазьдә чыгуы ямь өстенә ямь өсти.

20 нче гасыр башы татар меценатларының традицияләрен дәвам итүче милләтпәрвәр Тамир Алимбаевның дистә ел дәвамында бу гәзитне үз карамагында тотуы – күпләр акчага табынган бүгенге заманда, зур каһарманлык, күпләргә үрнәк тә.

Без бит ут күршеләр, киләчәктә Омск белән Төмән арасында элемтәләр югарырак баскычка күтәрелсен иде, уңышларыбыз, шатлыкларыбыз, уңай тәҗрибәбез, борчу-мәшәкатьләребез белән уртаклашып яшәсәк иде.

